**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2023-2024 нче уку елы**
**11 нче сыйныф**

**ВАРИАНТ 2**

**Максималь балл – 61**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **б** | **4** | **3** | **2** | **3** | **3** | **2** | **4** | беркөнне | Ике нокта |

## II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**6 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны кимetelә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкаль һәм андагы хайван атамасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) Авыр йөкне... тартыр. | 1) керпе |
| Ә) ... аягын күреп булмый. | 2) тычкан |
| Б) Араларыннан кара ... үткән. | 3) үгез |
| В) Койрыгына бассаң, .... дә чыелдый. | 4) мәче |
| Г) .... мөгезеннән эләктер. | 5) ат |

Җавап : **51423**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Каз ул – **(кулга/өйгә/гаиләгә)** ияләштерелгән иң борынгы йорт кошларының берсе. Халык **(элек-электән/борынгы заманнан/борынгы чордан)** **(чиксез / күп / гаять)** итеп каз асрарга яраткан. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк-ястыклар ясаганнар. Мендәрләрдән башка авыл йортын күз алдына китереп буламы соң? Икенчедән, каз итеннән бик **(оста/уңган/дөрес)** итеп әзерләгән каз бәлешенә, каз тәбикмәгенә, какланган казга җитәме соң!

Каз – туйларның да төп **(күрке/асылы/гаяте)**. Чөнки кыз яки улның туен үткәргәндә пар каз **(борынгыдан/элеккеге/бер вакыттан)** инде туйның хөрмәтле күчтәнәче булган. Хәер, бүген дә туйларда каз чыгару йоласы яшәп килә әле. Бу **(йола/гадәт/очрак)** ул эш кенә түгел, матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү чарасы да. *(Вакытлы матбугаттан)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктолар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Ак кәгазьдән каләм эзе тиз җуела,
Караны да, тушьларны да җуеп була.
Ташка язган сүзләрне дә еллар ала.
Күңелләргә язылган сүз мәңге кала.
Синең бурыч <....> күңелләргә сүзләр язу,
Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу.
Әзер юлдан үз көеңә бару җиңел.
Тигез җирдә юл салу да авыр түгел. (Э. *Мөэминова*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

**сызык**

4. *Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу* җөмләсеннән күчерелмә мәгънәле сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

**Алтын сүзләр**

5. Беренче куплеттан сыйфат фигыльләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

**Ташка язган, язылган, үткән заман сыйфат фигыльләр, барлыкта.**

**яз – тамыр, -ыл, -ган – модаль кушымчалар**

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

**өчен, көеңә**

7. *Ташка язган сүзләрне дә еллар ала* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз.
**(2 балл)**

**Еллар – гади ия, ала – гади хәбәр, ташка язган – аергыч, сүзләрне – туры тәмамлык. Бу-ике составлы җәенке, тулы, гади хикәя җөмлә.**

8.“*Күңелгә язылган матур сүз*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)